КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 29 декабрь

г.Казань

№ 1305

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга социаль түләүләрне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенция рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибен раслау турында» 2019 ел, 22 октябрь, 943 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга социаль түләүләрне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенция рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибен раслау турында» 2019 ел, 22 октябрь, 943 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «гамәлгә ашыру өчен» сүзләрен «гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү максатларында» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга социаль түләүләрне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенция рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибендә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Субвенция Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы өчен Федераль

казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә (алга таба – Казначылык) ачылган Татарстан Республикасы бюджетының бердәм счетына керә.»;

4 пунктта:

өченче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

дүртенче абзацта «, шулай ук халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри укыган һәм өстәмә һөнәри белем алган чорда» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин